Нуриев, В. Нияз Акмалны искә алу: [Чаллы үзәк китапханәсендә Нияз Акмалның 70 еллыгы уңаеннан әдәби чара узды] / В. Нуриев // Казан утлары. – 2024. – №4. – Б. 191.

**НИЯЗ АКМАЛНЫ ИСКӘ АЛУ**

Чаллы узэк китапханәсендә шагыйрь, прозаик, журналист Нияз Акмалнын тууына 70 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе булып узды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, берлекнең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, «Мәдәни җомга» газетасы, «Безнең мирас», «Казан утлары» журнапларының баш мөхәррирләре Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин, Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, Башкортстаннан шагыйрә Фәния Габидуллина, автор-башкаручы Риф Гатауллин, Г.Камал театры артисты Фәридә Сафина, композитор Айдар Тимербаев, җырчы Гөлдания Хәйруллина, Ниязньң бертуган апасы Энҗе ханым белән бертуган энесе журналист Нәсим Акмал һ.б. чыгыш ясады.